| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2023 г. Казань № 700-134/кс-2023

Зеленодольск муниципаль районының «СК-16» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2024-2028 елларга агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 15.12.2023 №59-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Билгеләргә:

әлеге карарның 1-2 нче кушымталарына туры китереп, ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы Зеленодольск муниципаль районының «СК-16» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «СК-16» ҖЧҖ) өчен агынты суларны транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар;

әлеге карарның 3 нче кушымтасына туры китереп, ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «СК-16» ҖЧҖ өчен агынты суларны транспортлауга 2024-2028 елларга озак сроклы җайга салу параметрларын.

2. Ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «СК-16» ҖЧҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә,

чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2023 № 700-134/кс-2023
карарына 1 нче кушымта

Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «СК-16» ҖЧҖ өчен 2024 елга
агынты суларны транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Чор | Транспортировка тарифы агынты су (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Казан шәһәренең су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызуның үзәкләштерелгән зонасындагы куллланучылар | | |
| 1 | «СК-16» ҖЧҖ (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алынмыйча күрсәтелгән) | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 8,44 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 10,85 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2023 № 700-134/кс-2023
карарына 2 нче кушымта

Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «СК-16» ҖЧҖ өчен 2025-2028 елларга*
агынты суларны транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Агынты суларны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Казан шәһәренең су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызуның үзәкләштерелгән зонасындагы кулланучылар | | |
| 1 | «СК-16» ҖЧҖ (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алынмыйча күрсәтелгән) | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 10,44 |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 10,44 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 10,44 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 11,21 |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 11,21 |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 11,25 |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 11,25 |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 | 12,05 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | кадәр | |

* 2025-2028 елларга агынты суларны транспортировкалау өчен тарифларга ел саен төзәтмәләр кертү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары нигезендә уздырыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2023 № 700-134/кс-2023 карарына 3 нче кушымта

## Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «СК-16» ҖЧҖ өчен 2024-2028 елларга агынты суларны транспортлауга тарифларны озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе* | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Норматив табыш дәрәҗәсе** | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе*** | электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «СК-16» ҖЧҖ | | | | | | |
| 1.1 | Агынты суларны транспортлау | 2024 | 9 202,72 | - | - | - | 0,21 |
| | | 2025 | - | 1 | - | - | 0,21 |
| | | 2026 | - | 1 | - | - | 0,21 |
| | | 2027 | - | 1 | - | - | 0,21 |
| | | 2028 | - | 1 | - | - | 0,21 |

* Озак сроклы җайга салуның икенче һәм аннан соңгы елларына операция чыгымнарының база дәрәҗәсе Россия ФТХ 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы белән расланган Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрнең 45 пунктында каралган формула буенча исәпләнә.

** «СК-16» ҖЧҖ өчен норматив табыш дәрәҗәсе билгеләнми.

*** Агынты суларны транспортировкалауга тариф өчен «су югалту дәрәҗәсе» энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткече билгеләнми.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге